| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА БИКУЛОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БИККОЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Биккол ав. **КАРАР**

«28» октябрь 2024 ел №2

Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлегендәге Биккол авылында үзара салым кертү һәм уздыру мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Биккол авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. ТР, Нурлат районы, Биккол авылы, Мәктәп урамы, 15а йорт адресы буенча урнашкан Биккол авыл мәдәният йортында Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлегенең Биккол авылында яшәүче барлык гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенын уздыруны 2024 елның 12 ноябрендә 09 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Биккол авылында яшәүче гражданнар өчен гражданнар җыенын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

3. Гражданнар җыенына чыгарылучы сорауны расларга:

«2025 елда үзара салым кертүгә Нурлат муниципаль районының Биккол авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә акча кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- торак пункт территориясен төзекләндерү.»

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Биккол авыл җирлеге башлыгы Р.Х. Әхмәтшина